МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Министерство образования и науки Республики Татарстан
Исполнительный комитет Арского муниципального района РТ
МБОУ «Шушмабашская СОШ »

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| МО учителей | Заместитель директора по | Директор |
| Файзрахманова Г.И. | Фатхрахманова Л.Ш | Шаймарданова Р.Г. |
| Протокол №1 | от "24" августа 2023г. | Приказ №160 |
| от "24" августа 2023 г. | | от "25" августа2023 г. |

**Рабочая программа**

по предмету «Родной (татарский) язык»
для обучающихся 10-11 классов
учителя родного языка и литературы
МБОУ «Шушмабашская СОШ»
Арского муниципального района РТ
Сабитовой Таслимы Афлатуновны

Шушмабаш 2023

# Туган (татар) тел фәнен федераль эш программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр

## 10 - 11 сыйныфлар

**Дәреслек, авторлар**:

1. Туган тел (татар теле). 10 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 80 б.

2. Туган тел (татар теле). 10 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 80 б.

3. Туган тел (татар теле). 11 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 92 б.

4. Туган тел (татар теле). 11 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 72 б.

### Методик тәкъдимнәр (дәреслекнең структурасы, игътибарга алынырга тиешле төп моментлар)

### Дәреслекнең структурасы

10-11 сыйныф дәреслекләре ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала. Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш», икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темалары урнаштырылды.

10 сыйныфта «Мин» лексик темасы кысаларында татар теленең фонетикасына, орфографиясенә, орфоэпиясенә, басым һәм интонациягә караган материал урын алды. «Тирә-як, көнкүреш» һәм «Туган җирем» темаларында лексикологиягә, лексикографиягә караган материаллар урнаштырылды. «Татар дөньясы» лексик темасына татар телендә сүз ясалышы һәм сүз төзелеше мәсьәләләрен эченә алган теоретик материал һәм бирем, күнегүләр кертелде.

10 сыйныф дәреслегендә урнаштырылган дәресләр барысы да бер төзелешкә ия. Дәрес башында, алдагы сыйныфларда өйрәнгән темага кагылышлы материалны искә төшерү өчен, бирем тәкъдим ителә. Алга таба кагыйдәне өйрәнү күздә тотыла. Шуннан

соң өйрәнгән һәм тулыландырылган материалны ныгыту өчен, күнегүләр эшләү каралган. Дәресләрдә бирем һәм күнегүләрнең саны һәм авырлык дәрәҗәсе төрлечә. Укытучыга сайлап алып эшләү мөмкинлеге зур.

10 сыйныф дәреслегендә текст белән эш, текстка анализ ясауга игътибар зур. Кабатлау, текст белән эш дәресләре авторлар тарафыннан нәкъ шул юнәлешне күздә тотып эшләнде. Әлеге төр дәресләр билгеле бер структурага ия. Укучыларга текстны тыңларга, текстның эчтәлегенә карата биремне үтәргә, текстны укырга һәм тел белеменең төрле тармакларына караган күнегүләрне эшләргә тәкъдим ителә. Дәресне язу һәм сөйләү күнекмәләрен камилләштерүгә юнәлтелгән биремнәр тәмамлый. Дәреслектә тест биремнәре дә зур урын алды. Алар кыска вакыт аралыгында төгәл итеп өйрәнелгән материалны кабатларга, булган белемнәрне тикшереп карарга ярдәм итәләр.

11 сыйныф дәреслегендә исә татар язуы тарихы, татар теленең диалектлары, мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре турында мәгълүмат бирелә. «Тирә-як, көнкүреш» темасында урнаштырылган дәресләрдә гади җөмлә синтаксисы өйрәнелә. «Туган җирем» темаларында кушма җөмлә синтаксисына караган материаллар урын алды. «Татар дөньясы» лексик темасына текст синтаксисы һәм стилистика мәсьәләләрен эченә алган теоретик материал һәм бирем, күнегүләр кертелде.

11 сыйныф дәреслегендә урнаштырылган дәресләр барысы да бер төзелешкә ия. Дәрес башында алдагы сыйныфларда өйрәнгән темага кагылышлы материалны искә төшерү өчен бирем тәкъдим ителә. Алга таба кагыйдәне өйрәнү күздә тотыла. Шуннан соң өйрәнгән һәм тулыландырылган материалны ныгыту өчен күнегүләр эшләү каралган. Дәресләрдә бирем һәм күнегүләрнең саны һәм авырлык дәрәҗәсе төрлечә. Укытучыга сайлап алып эшләү мөмкинлеге бар. Дәреслектә текст белән эш, текстка анализ ясауга игътибар зур. Кабатлау, текст белән эш дәресләре авторлар тарафыннан нәкъ шул юнәлешне күздә тотып эшләнде. Әлеге төр дәресләр билгеле бер структурага ия.

Укучыларга текстны тыңларга, текстның эчтәлегенә карата биремне үтәргә, текстны укырга һәм тел белеменең төрле тармакларына караган күнегүләрне эшләргә тәкъдим ителә. Дәресне язу һәм сөйләү күнекмәләрен камилләштерүгә юнәлтелгән биремнәр тәмамлый. Дәреслектә тест биремнәре дә зур урын алды. Алар кыска вакыт аралыгында төгәл итеп өйрәнелгән материалны кабатларга, ныгытырга ярдәм итәләр.

**10 класс** 34 сәг.

| 1 | Федераль эш программасында бирелгән тема | Теманың дәреслектә бирелеше (дәреслектәге тема яки дәреслек битләре яки текст исеме....) | Сәгать саны | Искәрмә<br>(автор кирәк санаса, предмет нәтиҗәләрен яки ресурсларга сылтамалар, һ.б. өсти ала) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 5–9 сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау | Кабатлау. Тест | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 4 – 10 битләр |
| 2. | Тел гыйлеме бүлекләре. Фонетика | Сузык авазлар системасы | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 11 – 28 битләр |
| | | Тартык авазлар | 1 | |
| | | Татар һәм рус телләрендә сузык һәм тартык авазлар | 1 | |
| | | Аваз һәм фонема | 1 | |
| | | Басым һәм интонация | 1 | |
| 3. | Орфография | Графика һәм орфография.Татар теленең орфографик принциплары | 2 | Дәреслек, 1 кисәк: 28 – 33 битләр |
| | | *Сочинение* | 1 | |
| 4. | Орфоэпия | Фән тармагы буларак орфоэпия. Орфоэпия нормалары турында төшенчә | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 34 – 36 битләр |
| 5. | Лексикология | Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 38 – 53 битләр; Дәреслек, 2 кисәк: 4 – 36 битләр |
| | | Полисемия. Сүзләрнең күп мәгънәлелеге | 1 | |
| | | Күчерелмә мәгънәләрнең төрләре | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төрки-татар килеп чыгышлы сүзләр һәм алынма сүзләр | 1 | |
| | | *Изложение* | 1 | |
| | | Төрле сүзлекләр һәм аларны куллану | 1 | |
| | | Мәкальләр, әйтемнәр, канатлы сүзләр<br>Сүзгә лексик анализ ясау | 1<br>1 | |
| | | *Тест* | 1 | |
| 6. | Фразеология | Фразеологизмнар. Татар телендә фразеологик әйтелмәләр | 2 | Дәреслек, 1 кисәк: 54 – 70 битләр |
| | | Фразеологизмнарны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре | 1 | |
| | | Икетеллелек шартларында татар теленең лексик һәм фразеологик составы баю | 1 | |
| | | *Проект эше* | 1 | |
| | | *Диктант* | 1 | |
| 7. | Морфемика<br>һәм сүз ясалышы | Татар телендә сүз ясалыш ысуллары | 3 | Дәреслек, 2 кисәк: 38 – 59 битләр |
| | | Кушымчалау ысулы белән яңа сүзләр ясалу | 2 | |
| | | *Сочинение* | 1 | |
| | | Сүзне составы ягыннан тикшерү | 1 | |
| 8. | Сөйләм, аралашу һәм сөйләм культурасы | Текст белән эш. Тасвирламалы текст төзү<br>«Кем булырга телим?» темасына эссе язу | 2 | Дәреслек, 2 кисәк: 59 – 68 битләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| . | | | **34 сәг.** | |

**11 класс** 34 сәг.

| 1 | Федераль эш программасында бирелгән тема | Теманың дәреслектә бирелеше (дәреслектәге тема яки дәреслек битләре яки текст исеме....) | Сәгать саны | Искәрмә (автор кирәк санаса, предмет нәтиҗәләрен яки ресурсларга сылтамалар, һ.б. өсти ала) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Тел һәм сөйләм | Татар теленең язу тарихы | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 4 – 21 битләр |
| | | Әдәби тел һәм диалект. Татар теленең диалектлары | 1 | |
| | | Татар теленең төрки телләр арасындагы урыны | 1 | |
| 2. | Тел гыйлеме бүлекләре. Морфология | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем сүз төркеме. Сыйфат сүз төркеме. Алмашлык. Сан сүз төркеме. Фигыль. Рәвеш | 3 | Дәреслек, 1 кисәк: 22 – 48 битләр |
| | | Ярдәмлек сүз төркемнәре | 1 | |
| | | Сүзгә морфологик анализ | 1 | |
| | | Диктант | 1 | |
| 3. | Синтаксис һәм пунктуация. Гади җөмлә | Сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзләр һәм җөмләләр арасындагы синтаксик бәйләнеш | 1 | Дәреслек, 1 кисәк: 50 – 82 битләр |
| | | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре | 2 | |
| | | Гади җөмлә төрләре һәм аларда тыныш билгеләре | 2 | |
| | | Гади җөмләгә синтаксик анализ | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Проект эше | 1 | |
| | | Сочинение | 1 | |
| 4. | Синтаксис.<br><br>Кушма җөмлә | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр | 1 | Дәреслек, 2 кисәк: 4 – 30 битләр |
| | | Иярченле кушма җөмләләр | 1 | |
| | | Сочинение | 1 | |
| | | Синтетик иярченле кушма җөмләләр<br><br>Аналитик иярченле кушма җөмләләр | 1<br><br>1 | |
| | | Кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләләрнең төзелеше | 2 | |
| | | Тест | 1 | |
| 5. | Стилистика | Функциональ стильләр. Фәнни стиль. Рәсми стиль | 1 | Дәреслек, 2 кисәк: 32 – 62 битләр |
| | | Сөйләмә стиль | 1 | |
| | | Матур әдәбият стиле | 1 | |
| | | Публицистик стиль | 1 | |
| | | Изложение | 1 | |
| | | Телнең төрле функциональ типларына караган текстлар | 2 | |
| | | Текстка анализ | 2 | |
| . | | | **34 сәг**. | |